| | | |
|---|---|---|
| «Рассмотрено»<br>Руководитель методического объединения учителей начальных классов<br>_______/Тухбатуллина Э.М./<br><br>Протокол № 1от<br>« 26 » августа 2017 г | «Согласовано»<br>Зам. директора по УР<br>_______/ Исмагилова Г.Т. /<br><br>« 28» августа 2017 г. | « Утверждено»<br>Директор школы<br>_______/Сабирзянова Г.Т. /<br><br>Приказ _№71_ от<br>«28 » августа 2017 г. |

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «САРМАНОВСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ, 4 а класс**
предмет, класс

**Салихова Нурия Миргасимовна, высшая квалификационная категория**
ФИО, категория

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1от
« 28» августа 2017 г.

2017 – 2018 учебный год

Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының
мәктәп методик берләшмә
җитәкчесе ______ Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча
директор урынбасары
______ Исмагилова Г,Т,.
"28" август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
______ Сабирзянова Г.Т..
Приказ № 71
« 28 » август 2017 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы МБГББУ " Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"

**Әдәби укудан эш программасы**

4 нче а сыйныф

**Салихова Нурия Миргасыйм кызы, югары квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы
утырышы беркетмәсе № 1
" 28 " август 2017 ел

2017 – 2018 нче уку елы

# Аңлатма язуы

**Әдәби уку**

4- а сыйныфы өчен эш программасы база дәрәҗәсендә белем бирү программасына нигезләнеп төзелде. Ул “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1 июль); “2004-2013 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт программасы” (2004 ел, 11 октябрь); Россия Федерациясенең 309-ФЗ номерлы Законы (2007 ел, 1 декабрь); Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандартына.- ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2008; Башлангыч гомуми белем бирү программаларына.Татар һәм рус телләре – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2010.; үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспективалы башлангыч мәктәп» концепциясенә; ”Әдәби уку” авторлык программасына. Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина.- Казан: Мәгариф-Вакыт, 2011; МБББУ «Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе» белем бирү программасы, “Укыту курсы һәм предметының эш программаларын раслау һәм эшләү тәртибе структурасы” турындагы нигезләмә, мәктәпнең 2017-2018 нче уку елына базис укыту планына нигезләнеп эшләнде.

Программа үтәлү өчен түбәндәге укыту-методик әсбаплар кулланыла:

1.Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче с-фы өчен дәреслек. 3 кисәктә.1 нче кисәк/(Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).-Казан: “ Мәгариф-Вакыт” нәшр.,2014.

2. Әдәби уку, татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче сыйныфында эшләүче укытучы өчен дәреслек/( Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).- Казан: “ Мәгариф-Вакыт”,2014.

**Укыту предметына гомуми характеристика. Укыту процессының төп характеристикасы.**

Әдәби уку фәненнән эш программасы “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәм икенче буын гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килә.

Әдәби уку – башлангыч мәктәптә төп предметларның берсе. Бу фән аша кече яшьтәге мәктәп баласына һәрьяклы белем бирелә. Башлангыч мәктәптә әдәби уку дәреслекләренең төп максаты – 4 ел уку дәверендә балада дөрес һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру, халык авыз иҗаты, язучы һәм шагыйрьләр әсәрләре белән якыннан таныштыру, чәчмә һәм шигъри әсәрләрне укып эстетик ләззәт алырга өйрәтү.

Төп идеяләр берничә һәм, бу идеяләрне тормышка ашырмыйча торып, максатка ирешергә мөмкин түгел.

<u>Беренче идея.</u> Уйдырмалар (мифлар) , халык авыз иҗаты белән автор әсәрләренең бәйләнеше турында дөрес күзаллау булдырырга кирәк.

<u>Икенче идея.</u> Әдәбият дәресләрендә, ашыкмыйча гына, әдәби образ төшенчәсен кертә бару сорала.

<u>Өченче идея</u>. Кече яшьтәге мәктәп баласын башта халык аваз иҗаты әсәрләре жанрларын, ә соңыннан әдәби жанрларын үзләрен дә аера белергә өйрәтергә кирәк.

Дүртенче идея. Кече яшьтәге мәктәп баласын шигъри әсәрләрне яратырга һәм аларны укып ләззәтләнә белергә өйрәтергә кирәк.
Укуга аңлы караш, уку күнекмәләре формалаштыру – "Әдәби уку" курсының **төп бурычы.**

Әдәби уку курсының төп этик бурычларыннан булган әхлак, экология, ватанпәрвәлык мәсьәләләре дәреслектә турыдан-туры үгет-нәсыйхәт бирү, махсус өйрәтү юлы белән хәл ителми, ә бәлки баланың табигать, тормыш-көнкүреш һәм яшәү тәҗрибәсенә нигезләнеп чишелә.

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге мәсьәләләрне хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле гомумдидактик бурычлар: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга тиеш.

2. Бала яшенә туры килә торган теоретик бурычлар: хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турышдагы автор әкиятләренең еш кына халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларак әйтелми);* халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

3. Әхлакый бурычлар: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү – байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;

4. Эстетик бурычлар: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;

5. Сөйләм телен үстерү бурычлары -текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка - бу «синең» әсәрне аңлау,идеяң икәнен җайлап төшендерү.

**Предметның укыту планындагы урыны**

Программа елга 102 сәгатькә (атнага 3 сәгать) каралган.
**Искәрмә:"**Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе" муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең "Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында " гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нче санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 4 нче а сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә.

**Әдәби уку фәнен үзләштерүгә планлаштырылган нәтиҗәләр**

| Предметлы УУГ | Метапредметлы УУГ | Шәхси УУГ |
|---|---|---|
| Әсәрне сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү;<br>әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү; төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белү; әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика; укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү; сүзлекләрдән файдалану; аерым бер элементы буенча китапта ориентлашырга ойрәтү *( авторы , исеме, “Эчтәлек” бите, иллюстрацияләр)*.<br><u>Укучы түбәндәгеләрне үзләштерә:</u><br>2-3 татар, рус, чит ил классигынын исемен; 2-3 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, алар язган әсәрләрне һәм эчтәлеген; үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен.<br>Алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану; китапның, төрле элементларына карап, эчтәлеген билгеләү; мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау; укылган әсәр геройларын тасвирлап сөйләү; сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу. | <u>Танып белү универсаль уку гамәлләре</u><br>үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү; логик фикерләү чылбырын төзү; тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү; мәгълүмат җиткерүче символларны уку; тормыш тәҗрибәсен кулланып, ситуациянең моделе буенча текст төзү; тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару; материаль объектлар (фишкалар) кулланып биремнәр үтәү; анализ, гомумиләштерү нигезендә нәтиҗә чыгару<br><u>Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре</u><br>-көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү; белгәнне һәм белмәгәнне аера белү; үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү; эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү; үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү; бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру; дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау; тормыш тәҗрибәсен куллану; үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү; укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү; тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү; күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы; күршең белән хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау; җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү. | Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру; дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасын күрсәтү; үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану; дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану; үз фикереңне әйтә белү; иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру; үз уңышларың-уңышсызлыкларың сәбәпләре турында фикер йөртү; кече яшьтәге мәктәп баласы үзе тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү. |

**Укыту предметының эчтәлеге**

| № | Бүлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп,бүгенге тормыш белән бәйлибез | 20 |
| 2 | Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз. | 10 |
| 3 | Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез. | 11 |
| 4 | Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз. | 7 |
| 5 | Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз. | 13 |
| 6 | Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә. | 18 |
| 7 | Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз. | 7 |
| 8 | Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз. | 16 |
| | **Барлыгы** | **102** |

**УКУ МАТЕРИАЛЫН КАЛЕНДАРЬ - ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**

**Әдәби уку**

| № | Дәрес темасы | Үткәрү вакыты | | Укучыларның эшчәнлеге төре һәм эш формалары |
|---|---|---|---|---|
| | | План | Факт | |
| **1.Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез (20 сәг.)** | | | | |
| 1. | Жир йөзендә яшәгән беренче кешеләр. Борынгы кеше әйләнә-тирә дөньяны ничек күз алдына китергән? | 1.09 | 4.09 | Дәреслек белән танышу. Шартлы билгеләрне истә калдыру .Сәнгатьле уку, сорауларга аңлап җавап бирү Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. |
| 2. | Җир ничек яралган? (легенда) | 4.09 | 4.09 | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау.. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. |
| 3. | Борынгы легендалар ни сөйли? “Күкнең күтәрелүе” | 6.09 | 6.09 | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау.. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. |
| 4. | Тотем агачлар. «Айдархан һәм сәхабәләр (легенда) | 8.09 | 8.09 | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. |
| 5. | Пәйгамбәрнең тууы. Абрек Абзгильдинның “Мөхәммәтнең тууы” картинасы. | 11.09 | 11.09 | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. |
| 6 | Туган як сылуы – ак каен | 13.09. | 13.09. | Өзекне анализлап сөйләү.Сорауга җавап табу,бирү. Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. |
| 7 | Туган як сылуы – ак каен | 15.09. | 15.09. | Шигырьне,әсәрдән өзекне ятлау. Өзекне анализлап сөйләү. Сорауга җавап табу,бирү. Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. |
| 8 | Абага чәчәге. Г.Кутуй “Рөстәм мажаралары” | 18.09. | 18.09. | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү. |
| 9 | | 20.09. | 20.09. | |
| 10 | Тотем хайваннар. “Ак байтал” (татар халык әкияте) Р.Шәмсетдинов. “Хан ауда” картинасы. | 22.09. | 22.09. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. |
| 11 | Тотем хайваннар. “Ак байтал” (татар халык әкияте) | 25.09. | 25.09. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. |
| 12 | Татар мифологиясендә Ак бүре. | 27.09. | 27.09. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татарстан гербы. | | | Видеофильм карау. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. |
| 13 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | 29.09. | 29.09. | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү |
| 14 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | 02.10 | 02.10 | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү |
| 15 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | 04.10 | 04.10 | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү. |
| 16 | Әкиятләрдә Ак елан. | 06.10 | 06.10 | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Сорауга җавап табу,бирү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. |
| 17. | Ф. Яруллин “Буар Елан” | 09.10 | 09.10 | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Сорауга җавап табу,бирү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. |
| 18 | Еланнар патшасы Шаһмара. | 11.10 | 11.10 | Әсәрне рольләргә бүлеп уку.Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Өзекне анализлап сөйләү. |
| 19. | | 13.10 | 13.10 | |
| 20. | **“**Тылсымлы әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез” темасын йомгаклау | 16.10 | 16.10 | Сорауларга җавап бирү (тест) |
| **2.Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз. (10 сәг.)** | | | | |
| 21 | Борынгы шагыйрь Кол Гали. Ш.Галиев “Кол Галигә”, Р.Шәмсетдинов. “Кол Гали” картинасы, “Тоткын Сөембикә җыры” | 18.10 | | Борынгы шагыйрь Кол Гали иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү |
| 22 | Кыссаи Йосыф. | 20.10 | | Борынгы шагыйрь Кол Гали иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү Шигырьне,әсәрдән өзекне ятлау. Өзекне анализлап сөйләү. |
| 23 | Без – татар балалары. Г. Латыйпның “Минем нәсел”, Э. Шәрифуллинаның “Без – татар балалары” | 23.10 | | Көзге табигать мизгелләренең автор әсәрләрендә би-релешен өйрәнү, чагыш-тыру, сынландырулар, строфа турында белем-нәрне ныгыту |
| 24 | Нәсел агачы. Ә.Рәшит “Нәсел агачы,Ф.Гыйрфанов. “Болгар ханнары шәҗәрәсе” картинасы, Х.Камалов. “Археолог”. | 25.10 | | Нәсел агачы, нәсел шәҗәрәсе турында белү. Бик борынгы нәсел шәҗәрәсе үрнәкләре белән танышу. |
| 25 | Су асты патшалыгында. Н. Сәйяр “Айсылу” | 27.10 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. |
| 26. | | 06.11 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27 | Су кызы. | 08.11 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 28 | Айсылу – бәхетле бала. | 10.11 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. |
| 29 | | 13.11 | | |
| 30 | Г.Гыйльманов “Җавапсыз легенда» Тест. | 15.11 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Язучы турында видеофильм карау. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. |
| **3. Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез (.11с.)** | | | | |
| 31 | Җирдә миңа ни кирәк?<br>Ш.Галиев “Жирдә мина ни кирәк?”,<br>Ш.Галиев “Алсу дөнья”. | 17.11 | | “Кеше яшәеше өченниләр кирәк?” соравына җавап табу. Авторның биография белән танышу, аның әсәрләрен уку, анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Үз фикерләрен дәлилләп аңлату. Уңай һәм тискәре геройларны аеру. Геройларга характеристика |
| 32 | Шәехзадә Бабич шигырьләре. Ш.Бабич “Габдулла әфәнде Тукаев”, “Тын төн”. | 20.11 | | XX гасыр башында яшәп иҗат иткән шагыйрьләр-нең берсе булган Шәехза-дә Бабич иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү |
| 33 | Көзге табигать мизгелләре.<br>. К.Булатова “Кичә генә”, Р.Корбан “Ярдәм итик”, Г.Рәхим “Көзге урман”, М.Усманов “Урман күле”,<br>О.Кульпин “Зәңгәр култык” | 22.11 | | Көзге табигать мизгелләренең автор әсәрләрендә бирелешен өйрәнү, чагыш-тыру, сынландырулар, строфа турында белемнәрне ныгыту |
| 34. | | 24.11 | | |
| 35 | Кышкы сандугач. | 27.11 | | Укучыларны безнең якта кышлаучы кошлар белән таныштыруны дәвам итү; |
| 36 | Иртә яме, иртә моңы- җан азыгы. | 29.11 | | Укучыларны режим белән яшәргә күнектерү |
| 37 | Иртә яме, иртә моңы- җан азыгы. | 01.12 | | Укучыларны режим белән яшәргә күнектерү |
| 38 | Әнкәм портреты. | 04.12 | | Галәмдә табигать һәм кешенең бербөтен булуын, кеше һәм табигать арасын-да бәйләнешләрне аңлату, туган як кадерен хәтта хайваннар да белүен төшендерү |
| 39 | Иң матур сүз. | 06.12 | | Сүз көче, сүзне уйлап әй-тергә кирәклеген аңлату.<br>Тәмле телле, ихлас сүзле шәхес тәрбияләү. |
| 40 | Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә. | 08.12 | | Икенче һәм өченче сый-ныфларда өйрәнгән язу-чылар иҗатын искә төше-реп, яңа әсәрләре белән таныштыру барышында иҗат үзенчәлекләрен бил-гели белергә өйрәтү |
| 41 | “Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез” бүлеген кабатлау | 11.12 | | Укучыларның тема буенча<br>белем һәм күнекмәләрен системага салу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4. Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз.( 7 сәг)** | | | | |
| 42 | Газаплы язмыш. Г.Галиев “Бибкәй аланы” | 13.12 | | Борынгы заманнарда яшәгән балалар тормышының үзенчәлекле якларын, авыр тормышта яшәү сәбәпләрен аңлату |
| 43. | Кечкенә хезмәтче.<br>Ф.Әмирхан “Кечкенә хезмәтче”. | 15.12 | | Ф.Әмирханның”кечкенә хезмәтче” хикәясе аша ба-ларның авыр хезмәте белән таныштыру, әсәргә карата мөнәсәбәтләрен ачык итеп аңлата белүләренә ирешү |
| 44. | Күз яшьле балачак. К.Нәҗми “Нәсимәнең беренче эш көне”,<br>В.Маковскийның “Күрешү” картинасы. | 18.12 | | Тема уртаклыгын табу, дәлилләп аңлата алуларына ирешү Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Хикәяне ике кисәккә бүлү, бүлекләргә исемнәр уйлау.<br>Картина буенча хикәя төзү. |
| 45 | Д.Аппакова “Кечкенә Бануның тарихы” | 20.12 | | Тема уртаклыгын табу, дәлилләп аңлата алуларына ирешү |
| 46 | Каникуллар - рәхәт вакыт.<br>Г.Ибраһимов “Укудан кайткач”.<br>Ф.Решетниковның “Каникулга кайтты” картинасы. | 22.12 | | Кышкы каникул көннәре, бу вакытның ни өчен бик рәхәт булуын ачыклау<br>Картина буенча хикәя төзү. |
| 47 | Балачак хатирәләре.<br>С.Хәким “Яратам мин”. | 08.01 | | Һәрбер кешенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге булуга инандыру. Шул вакыт эчендә сагынып искә алырлык мизгелләр булуы турында ажлату. |
| 48 | Матурлык дөньяны коткара. М. Мәһдиев “Бәхилләшү” (өзек), Зөлфәт “Кыз тавы” теманы йомгаклау. | 10.01 | | Зөлфәт һәм М.Мәһдиев әсәрләре белән таныштыру |
| **5. Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз. (13 сәг.)** | | | | |
| 49 | Көннәрем гөрләп торсын..<br>В.Хәйруллина “Хәерле көн”,<br>Р.Миңнуллин “Иртән иртүк”. | 12.01 | | Көнне исәнләшү, хәерле иртә теләүдән башласаң, һәр эшең уңай булыр, максатыңа да ирешә алачаксың, дип балаларны инандыру. Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, сорауларга җавап бирү. Строфадагы юллар санын билгеләү, рифмалашкан сүзләрне табу. |
| 50 | . Каен-урман чибәре.<br>С.Гафарова “Көз”.И.Шишкинның “Каенлык”, К.Максимовның “Каенлык” картиналары | 15.01 | | Татар халкы борын-борын-нан табынган , тормышта еш файдаланган каен ага-чы турында өйрәнүне дәвам итү Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Үз фикерләрен дәлилләү.<br>Картина буенча хикәя төзү. |
| 51 | | 17.01 | | |
| 52 | Бөтен дөнья ак кына.<br>Р.Вәлиева “Бөтен дөнья ак кына”. | 19.01 | | Табигатьнең иң саф, гүзәл мизгелләрнең берсе – кыш турында күзаллауларын үстерү. Авторларның табигать фасылларына багышланган әсәрләре белән танышу Сәнгатьле итеп, тиешле тизлектә уку, сорауларга җавап бирү. |
| 53 | Язгы моң.<br>Р.Гыйззәтуллин “Язгы моң”. | 22.01 | | Язгы табигать күренешләрен тасвирлаган әсәрләр уку, рәссам М.Хәйретдинов иҗаты белән танышу. Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | М.Хәйретдиновның “Ана булу”, “Назлылык” картиналары. | | | биремнәрне үтәү. Картина буенча хикәя төзү. |
| 54 | Серле күк. Р.Мингалим “Бүген төнлә күккә кара”. | 24.01 | | Күк йөзенең серләрен әдәби әсәрләр аша ачу Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләү. Яз һәм көзне үзара чагыштырып, контраст билгеләрен табу. |
| 55 | Матурлык дөньясы. Л.Исхакова.”Шомырт чәчәкләре ак кына” | 26.01 | | Матурлыкны аңлый, аңа соклана, саклый белү телә-ге уятырлык әсәрләр белән танышу Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Чагыштырулар табу. Үз фикереңне дәлилләү. |
| 56 | Туган як – Идел көзгесендә. К. Булатова “Шу шы яктан, шушы туфрактан без”.К.Максимовның “Идел көзгесендә” картинасы. | 29.01 | | Татарстанның горурлыгы, байлыгы булган Идел ел-гасы турында белемнәрне арттыру Әдәби әсәрләрнең башка сәнгать әсәрләре белән бәйләнешен ачыклау, сәнгатьле уку; укыган текст, рәсемнәрне чагыштырып, сорауларга җавап бирү.Картина буенча хикәя төзү. |
| 57 | Туган көнгә – салават күпере Батулла. “Салават күпере кайда йоклый?” | 31.01 | | Укучыларны туган көннең кешеләр тормышында зур, эчтәлекле бәйрәм итеп билгеләп үтелүен күрсәтү. Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Әкиятнең эчтәлеген тулысынча сөйләү |
| 58 | Табигать – серле дөнья Җ.Дәрзаман “Бөҗәкләр белән сөйләшү”. | .02.02 | . | Балаларга табигать серләрен ачарга ярдәм итү Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. “Табигатькә ничек ярдәм итәргә?” дигән темага әңгәмәдә катнашу, рәсем ясау. |
| 59 | Батулла “Терек-терек кырмыска” | 05.02 | | Балаларга табигать серләрен ачарга ярдәм итү. Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Әкиятнең эчтәлеген тулысынча сөйләү |
| 60 | Аккошлар - сак кошлар. Г.Хәсәнов “Аккош”, Р.Фәйзуллин “Быелгы яз” А.Тимергалина “Аккош”. | 07.02 | | Г.Хәсәнов иҗаты белән таныштыру, аның күзәтүләре аша аккошлар тормышы белән танышу |
| 61 | Сандугач-табигать жырчысы. Р.Миңнуллин “Атказанган сандугач”. | 09.02 | . | Табигатьнең гүзәл җырчысы – сандугач белән таныштыру. Авторларның аларга багышлап язган әсәрләрен уку Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Сандугач тавышын тыңлау |
| | **6. Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә. (18 сәг.)** | | | |
| 62 | Тылсымлы, кодрәтле үлән. Г.Хәсәнов “Абага” | 12.02 | | Абага үсемлеге, аның хикмәтләре белән таныштыру. Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләү. |
| 63 | | 14.02 | | |
| 64 | Кирлемән мажаралары Р.Хафизова “Кирлемән». | 16.02 | | Кешедәге кирелек сыйфатының тискәре күренеш булуын, үз-үзеңне тәртипле, инсафлы тотарга комачаулык итүен төшендерү Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.. |
| 65 | Кирлемән мажаралары | 19.02 | | Кешедәге кирелек сыйфа-тының тискәре күренеш булуын, үз-үзеңне тәртип- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ле, инсафлы тотарга кома-чаулык итүен төшендерү |
| 66 | Урман докторы. Ж.Тәржеманов “Тукран малае Шуктуган”. | 21.02 | . | Табигатьнең күркәм бер кошы-тукран белән таныштыру. Аның яшәеше, кешеләргә китергән файдасы турында күзаллау булдыру Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Әкиятнең эчтәлеген тулысынча сөйләү |
| 67 | | 26.02 | | |
| 68 | Гөмбәләр серен белү кирәк. Н.Сладков “Тыштан ялтырый, эчтән калтырый”.Е.Зуевның “Урман хәзинәләре” картинасы | 28.02 | | Табигать үсә торган күптөрле гөмбәләр семялыгыннан ашарга яраклы гөмбәләрне танырга өйрәтү Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр турында әңгәмәдә катнашу.Картина буенча хикәя төзү. |
| 69 | | 2.03 | | |
| 70 | Бану әби сабагы. К.Тимбикова “Бану әби сабагы”. | 5.03 | . | Язучы Кояш Тимбикова әсәрләре белән танышу Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Әсәрнең эчтәлеге буенча план төзү. Хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләү |
| 71 | | 07.03 | . | |
| 72 | Аш пешерү хикмәтләре. | 09.03 | | Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Хикәянең эчтәлеген тулысынча сөйләү |
| 73 | Татар халык ашлары. Э.Шарифуллина “Тормыш яме”, В.Кочуновның “Бәйрәмчә натюрморт” картинасы. | 12.03 | | Татар халкының милли ризыклары белән язучы һәм рәссамнар иҗаты ярдәмендә таныштыру, гореф-гадәтләрен аңлату Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Картина буенча хикәя төзү. |
| 74 | Балалар дөньясы. Д.Гайнетдинова “Батыр Хәбир”. | 14.03 | . | Г.Гыйльманов, Д.Гайнетдинова, Л.Гыймадиева әсәрләрендә балалар тормышының чагылышы белән таныштыру, авторларның ни әйтергә теләвен ачыклау |
| 75 | . Бүрек-нәни көчек. Г.Гыйльманов “Минем исемем Бүрек” | 16.03 | | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәре белән танышу дәвам итү |
| 76 | | 19.03 | | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәре белән танышу дәвам итү |
| 77 | Бүрек - ышанычлы сакчы. В.Нуриев “Ачуланма инде, Илһам!” | 21.03 | | Максатларны ачыклау. Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү |
| 78 | | 23.03 | | |
| 79 | “Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә” бүлеген йомгаклау | 04.04 | | Уңай һәм тискәре геройларны аеру. Геройларга характеристика бирү. Тест биремнәрен үтәү. |
| **7. Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз. (7 сәг.)** | | | | |
| 80 | Язучы катнашында үткән “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы. Р.Вәлиев “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”. | 06.04 | | Укучыларны якташ язучылар иҗаты, тормыш юлы белән таныштыру |
| 81 | Бәбкә үстерү хикмәтләре. Р.Вәлиев “Эт кояшы”, К.Насыйри. “Каз итен, коймакка төреп, | 09.04 | | Сәнгать дөньясының үзенә хас үзенчәлекләрен аңлату |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | каймакка манып ашау”. | | | |
| 82 | Чыпчыкның да үз җыры бар<br>Мөҗәһит “Кемнең сайрыйсы килми?”,<br>К.Сибгатуллин“Чыпчык”<br>И.Туктар“Букет”, “Бер каен үсә”,<br>Р.Корбан“Курай”. | 11.04 | | Гади генә күренешләрдән дә матурлыкны күрә һәм бәяли белергә өйрәтү<br>Сорауларга төгәл җавап бирү. Фикерләрне дәлилләп,аңлатып бирү.<br>Шигырьләрне чагыштыру |
| 83 | Яз галәмәтләре<br>Р.Әхмәтҗанов “Безнең шигырь”,<br>И.Гыйләҗев “Охшашлык”. | 13.04 | | Язгы табигать мизгелләрен яктырткан әсәрләр аша табигатьтәге үзгәрешләр-не, язның төп билгеләрен табарга өйрәтү, кеше күңе-ленең кайсы халәтен яз белән чагыштыруларын аңлату |
| 84 | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” | .16.04 | | Уңай һәм тискәре геройларны аеру. Геройларга характеристика бирү.Картина буенча хикәя төзү.Тест биремнәрен үтәү. |
| 85 | В.Аршиновның “Яз билгеләре” картинасы.Теманы йомгаклау. | 18.04 | | |
| 86 | Арадаш аттестация | 20.04 | | |
| | **8. Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган илтурында уйланабыз. (16 сәг.)** | | | |
| 87 | Һәркемгә үз Ватаны кадерле.<br>Р.Вәлиев “Ватаным”<br>Билгесез рәссамның “Сөембикә ханбикә үз гаиләсе белән” картинасы. | 23.04 | | Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Җыр тыңлау.<br>Картина буенча хикәя төзү. |
| 88 | Татарстан флагы.<br>Р.Харис “Татарстан әләме”<br>В.Худяковның “Сөембикә ханбикәне Казаннан алып китү” картинасы. | 25.04 | | Дәүләт символлары турында әңгәмәдә катнашу. Әсәрләрне уку, анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү.Картина буенча хикәя төзү. |
| 89 | Зур тарихлы батыр халкым.<br>Н.Арсланов “Халкыма”, Г.Морат “Чит тел” К.Венигның “Казанны яулап алу” картинасы. | 27.04 | | Парларда эшләү.Шигырьләрне аңлап, сәнгатьле уку өстендә эш.Рамка белән эшләү.Картина буенча хикәя төзү. |
| 90 | Г.Вәлиева “Карт алаша колагы”. | 30.04 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 91 | Балачакнын онытылмаслык истәлекләре.<br>М.Мирза “Балачак хатирәсе”, С.Хәким “Тегермән стенасындагы язулар”. | 02.05 | | Элекке заманнарда яшәгән балалар тормышы аша илебез тарихын аңлату<br>Әсәрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. Хикәянең эчтәлеген сөйләү.Фикерләрне дәлилләп, аңлатып бирү. Төркемнәрдә эшләү |
| 92 | Авыр елларда.<br>Р.Фәйзуллин “Минем әти”, Н.Каштан “Әрем исе”. А.Ширяеваның “Авыр | 04.05 | | Сугыш чоры балалары кичергән авырлыкларны әдәби образлар язмышы ярдәмендә аңлату<br>Әсәрләрне укып анализлау, сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | елларда" картинасы. | | | Картина буенча хикәя төзү. |
| 93 | Н.Каштан "Әрем исе" | 07.05 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 94 | Сөю – иң куәтле дәва. Р.Вәлиева "Онытма", М.Җәлил "Дару". | 11.05 | | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтү |
| 95 | Кыю очучылар Г.Кутуй"Яшен", Ш.Рәкыйпов "Төнге очыш".А.Пластовның "Фашист самолеты очып үтте" картинасы. | 14.05 | | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтү |
| 96 | | 16.05 | | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтү Картина буенча хикәя төзү |
| 97 | Ш.Рәкыйпов "Төнге очыш" | 18.05 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 98 | Һәркемгә якын ул туган як Һәркемгә якын ул туган як. Г.Мөхәммәтшин "Туган як", М.Галиев "Туган як", Н.Исәнбәт "Туган ил", Р.Харис "Туган җирем".Теманы йомгаклау. | 21.05 | | Туган җирне, туган якны ярату турында сөйләшү Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. |
| 99 | Якташ язучылар иҗатын өйрәнәбез | 23.05 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 100 | | 25.05 | | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. |
| 101 | "Серле ачкыч" мәктәп клубы утырышы. | 28.05 | | Темалар буенча үткән материаллар ныгыту, сорауларга телдән җавап, диалог төзү, күнегүләр эшләү. |
| 102 | Ел буе өйрәнгәннәрне йомгаклау. Олимпиада .Йомгаклау. | 30.05 | | "Серле ачкыч" мәктәп клубының чираттагы утырышы Сорауларга төгәл җавап бирү. Фикерләрне дәлилләп, аңлатып бирү. Төркемнәрдә эшләү.Олимпиада биремнәрен үтәү. |

**Әдәбият**

1. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф]: Дәреслек. 3 кисәктә. 1 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт" нәшрияты, 2014.
2. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 2 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014.
3. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 3 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014
4. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Методик кулланма. — Казан:«Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014

**Кушымта**

## Укучылар эшчәнлегенең бәяләү нормалары:

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес, эчтәлеге ягыннан эзлекле һәм тулы диалогик сөйләм төзегәндә, «5»ле куела.

Бирелгән ситуация яки лексик тема буенча репликаларның әйте¬лешендә һәм аерым сүзләрнең грамматик формаларында 2 — 3 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлекле диалогик сөйләм төзегәндә, «4»ле куела.

Өстәмә сораулар ярдәмендә генә әңгәмә кора алганда, репликаларның әйтелешендә һәм сүзләрнең грамматик формаларында 4 — 6 хата җибәреп, эчтәлеге ягыннан эзлексез диалогик сөйләм төзегәндә, «3»ле куела.

Бирелгән ситуаиия яки лексик тема буенча диалог төзи алмаганда, «2»ле куела.

**Монологик сөйләмне бәяләү**

Әйтелеше һәм грамматик төзелеше ягыннан дөрес һәм эчтәлеге ягыннан тулы, эзлекле монологик сөйләм өчен «5»ле куела.

Аерым сүзләрнең әйтелешендә, грамматик формаларында яки жөм¬лә төзелешендә 2 — 3 хатасы булган, эчтәлеге ягыннан тулы монологик сөйләм өчен «4»ле куела.

Сүзләрнең әйтелешендә, җөмлә төзелешендә 4 — 6 хаталы, эчтәлеге ягыннан эзлекле булмаган монологик сөйләм өчен «3»ле куела.

Лексик темага монолог төзи алмаганда, «2»ле куела.

**Ишетеп аңлауны бәяләү**

Тыңланган татар сөйләмен тулаем аңлап, төп эчтәлеген сөйләп бирә алганда, «5»ле куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген якынча дөрес сөйли алганда, «4»ле куела.

Тыңланган татар сөйләмен аңлап, эчтәлеген өлешчә генә сөйли алганда, «3»ле куела.

Тыңланган татар сөйләменең эчтәлеген тулаем аңламаганда, «2»ле куела.

**Укуны бәяләү**

Текстның эчтәлеген тулаем аңлап, сәнгатьле итеп укыганда, «5»ле куела.

Текстның эчтәлеген аңлап, сәнгатьле һәм аңлаешлы итеп укыганда, әмма 2—3орфоэпик хата (авазларның әйтелешен бозу, басымны дөрес куймау, интонацияне сакламау) булганда, «4»ле куела.

Текстның эчтәлеген өлешчә аңлап укыганда, 4 — 6 тупас орфоэпик хата булганда, «3»ле куела.

Текстның эчтәлеген тулысынча аңламыйча, орфоэпик кагыйдәләр¬не бозып укыганда, «2»ле куела